Рус мәктәбенең татар төркемендә укучы балалар өчен
татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре

8нче сыйныф
Үткәрү вакыты 180 мин.

**I. ТЕСТ:**

1. **Билгеләмәгә туры килгән жанрларны күрсәтегез. (**1әр балл**):**

а) Гарәп теленнән кергән сүз – икеюллык шигырь. Алар халык иҗатының башка төрләреннән язма әдәбиятка якын торулары белән аерылалар. Татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Аның нигезендә күпчелек очракларда кайгылы вакыйгага ята. ____________________________________________

ә) Латин теленнән кергән сүз, эпик, прозаик жанр. Могҗизалыкка, фантастик күзаллауга нигезләнгән һәм сөйләүче ягыннан да, тыңлаучылар тарафыннан да кайчандыр тормышта булган хәл төсендә кабул ителә торган хикәят.

Риваятьләрдән алар чынбарлыкка нинди мөнәсәбәттә булулары, тарихи мәгълүматны, чынбарлыкны чагылдыру дәрәҗәсе белән аерыла. Әкияттән аермалы буларак, аларда нигез булып чыннан да кайчандыр булган хәлләр ята.

________________________________________________________

б) Халык иҗатының борынгы жанрларыннан берсе, могҗизалы һәм маҗаралы вакыйгаларга, шулай ук көнкүрешкә бәйләнешне хәлләргә корылган фантастик әсәр, реаль һәм фантастик алымнар белән сурәтләнгән кешеләр, хайваннар, мифик образлар аша халыкның үткән тормышын, киләчәккә карата хыял һәм омтылышларын чагылдыручы чәчмә халык авыз иҗаты әсәре.

_______________________________________________________________

**2. XIX-XX йөзләр чигендә иҗат иткән автор: (**1 балл)

а) Әмирхан Еники
б) Ризаэддин Фәхреддин
в) Кол Гали

**3. М.Гафури әсәре: (**1 балл)
а) “Ана бәйрәме”
б) “Ана”
в) “Ана догасы”

**4. Татар халык авыз иҗатында булмаган жанрларны билгеләгез:**
(1 балл)

а) поэма, әкият,
ә) бәет, дастан,
б) драма, повесть
в) әкият, җыр

## II. <u>БИРЕМНӘР:</u>

1. **“Сак-Сок” бәете, аның жанр үзенчәлеге турында белгәннәрегезне язгыз. Фикерләрегезне әлеге бәет мисалында дәлилләгез (8 балл).**

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**2. Психологизм төшенчәсенә билгеләмә бирегез. Мисаллар нигезендә аңлатыгыз.** (8 балл).

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**3. Бу юллар кайсы әсәрдән? Авторын, әсәрнең исемен, жанрын языгыз. Төп геройны характерлагыз.** (8 балл).

Кемдер түр тәрәзәне ачып җибәрде, Зөбәрҗәтнең ал шәфәкъ сеңгән челтәр-

пәрдәләрен селкетеп өйгә таң җиле бөркелде... Таңның тәүге саф тирбәлеше өлгергән иген исләре белән Нуриасманың караваты янына сөрлегеп үкседе, аның ак маңгаен, әле ябылып бетмәгән күзләрен, битләрен һәм иреннәрен сыйпады, иркәләде дә алгы өйнең ачык тәрәзәләреннән чыгып очты. Ул аның тән һәм җан җылысын сеңдереп, Нуриасма гомере буе омтылган, җанына рәхәтлек, йөрәгенә көч алган Ык буйларына, болыннарга, әрәмәләргә, иген басуларына шул җылыны таратырга очты, аның инде бүтән беркайчан да алар янына килмәячәген хәбәр итәргә ашыкты...

**4. Бирелгән сүзләрне җыеп, шигырь юлларын төзегез. Авторын, шигырьнең исемен, хис-тойгыларны билгеләгез.** (10 балл)

Йөз, йөз, йөз, йөз, кабат, кабат, кабат, кабат, кул, уйланам, әйләнәм-тулганам, бирәм, бирәм, юл, кешегә, сызланам, кешегә.

**Барлыгы 40 балл**